МИНИСТЕРСТВ ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МОНОСЭБОТЛЭРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

РАСПОРЯЖЕНИЕ | БОЕРЫК

07.07.2023 | Казан ш. | № 1860-р

Газ бүлү газүткәргеченең саклык зонасын үзгәртү һәм Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасының Югары Ослан, Кама Тамагы (өлешчә), Яшел Үзән (өлешчә) муниципаль районнары территорияләрендәге газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) саклык зоналары чикләрен раслау турында” 25.12.2014 № 3004-р карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 статьяларына, «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, “Күчемсез милекнең дәүләт теркәве турында” 2015 елның 13 июлендәге № 218-ФЗ Федераль законның 32 статьясына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп, «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате нигезендә, «Татарстан Республикасының техник инвентаризация һәм кадастр эшләре бюросы» АО башкарган документациягә туры китереп, «Фонд пространственных данных Республики Татарстан» ДБУның (№ 04А-04/1434 от 14.06.2023) хатын искә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы карар чыгарды:

1. «Газпром трансгаз Казань» ЖЧҖ милкендә Татарстан Республикасының Югары Ослан муниципаль районы территориясендә булган, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасының Югары Ослан, Кама Тамагы (өлешчә), Яшел Үзән (өлешчә) муниципаль районнары территорияләрендәге газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) саклык зоналары чикләрен раслау турында” 25.12.2014 № 3004-р карары (алга таба - карар № 3004-р) нигезендә урнаштырылган 10479 инвентарь номерлы бүлгеч газүткәргечнең саклык зонасын, 16:15:000000:3602, 16:15:000000:3209, 16:15:180801:963, 16:15:180801:997, 16:15:030701 кадастр номерлы җир кишәрлекләрендә күрсәтелгән газүткәргечнең 434 м.ына демонтаж ясалу һәм 612 м.га монтаж ясау сәбәпле «Татарстан Республикасының техник инвентаризация һәм кадастр эшләре бюросы» АҖ башкарган территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүматка, җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталарының координаталары исемлегенә туры китереп үзгәртергә. Бүлгеч газүткәргечнең саклык зонасы озынлыгы гомуми мәйданы (74532 ± 96) кв.м.лы территория рәвешендә 18287 м.ны тәшкил итә.

2. Инвентарь номеры 10479 булган бүлгеч газүткәргечне эксплуатацияләү срогында әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән газ бүлү челтәрләре объектының саклау зоналары чикләренә тулысынча яки өлешчә туры килгән җир кишәрлекләренә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

3. «Татарстан Республикасының техник инвентаризация һәм кадастр эшләре бюросы» АҖ башкарган территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүмат, җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталарының координаталары исемлеге нигезендә № 3004-р карарга (Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 05.07.2023 № 1848-р карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Югары Ослан муниципаль районы территориясендәге «Зеленодольскгаз»ның әлеге карарның 1 нче кушымтасындагы инвентарь номерлы, 329,659 км. озанлыктагы газ бүлгеч газүткәргече, гомуми мәйданы 1,39019 км.лы территориядә «Татарстан Республикасының техник инвентаризация һәм кадастр эшләре бюросы» АҖ башкарган җир өсте һәм җир асты объектларының саклык зонасы картасындагы (планда) мәгълүматлар буенча»;

әлеге карарның 1 нче кушымтасындагы 10479 инвентарь номерлы бүлгеч газүткәргечкә туры килгән юлны әлеге карарның кушымтасы редакциясендә бәян итәргә (бастырып чыгару каралмаган).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.А.Кыямовка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**